Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Чистай авыл җирлегенең Луч поселогындагы
гражданнар җыены

КАРАР

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай авыл җирлеге составына керүче Луч поселогындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 26 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2021 елда Чистай муниципаль районының Чистай авыл җирлегенең Луч поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча 2020 елның 18,20,24,26 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- территорияне төзекләндерү – Луч поселогында парк төзү (брусчаткадан җәяүлеләр өчен юл салу, эскәмияләр, фонарьлар, чүп баклары, ПГС, бордюрлар, цемент сатып алу, килешү буенча түләү),
- территорияне төзекләндерү - Гагарин урамы буенча тротуар юлы төзелешен дәвам итү (ПГС, бордюр, цемент сатып алу, килешү буенча түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 937 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 528 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

**«**РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 477 катнашучысы тавыш бирде;

**«**КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 51 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Чистай муниципаль районының Чистай авыл җирлегенең Луч поселогындагы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. «2021 елда Чистай муниципаль районының Чистай авыл җирлегенең Луч поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән ризалашасызмы?» дигән сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

- территорияне төзекләндерү – Луч поселогында парк төзү (брусчаткадан җәяүлеләр өчен юл салу, эскәмияләр, фонарьлар, чүп баклары, ПГС, бордюрлар, цемент сатып алу, килешү буенча түләү),

- территорияне төзекләндерү - Гагарин урамы буенча тротуар юлы төзелешен дәвам итү (ПГС, бордюр, цемент сатып алу, килешү буенча түләү).

3. Чистай муниципаль районының Чистай авыл җирлегенең Луч поселогы территориясендә 2021 елда үзара салымны, Чистай муниципаль районының Чистай авыл җирлегенең Луч поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән тыш, 200 сум күләмендә кертергә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- территорияне төзекләндерү – Луч поселогында парк төзү (брусчаткадан җәяүлеләр өчен юл салу, эскәмияләр, фонарьлар, чүп баклары, ПГС, бордюрлар, цемент сатып алу, килешү буенча түләү),

- территорияне төзекләндерү - Гагарин урамы буенча тротуар юлы төзелешен дәвам итү (ПГС, бордюр, цемент сатып алу, килешү буенча түләү).

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элеп чыгу юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Чистай авыл җирлеге
башлыгы ________________ Р.М. Мәгъсүмов